ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм “Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 4, 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 1; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 4, № 7, № 12 (IV өлеш) “рәсми басма” дигән тамга белән” сүзләрен төшереп калдырырга, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналында” сүзләрен “Татарстан Республикасы законнары җыентыгы” журналында” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма

басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 7, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә “аның Президиумы” сүзләрен “аның Президиумының норматив характерга ия” сүзләренә алмаштырырга, “газеталарында” сүзеннән соң “Татарстан Республикасы законнары җыентыгы” журналында” сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә “Татарстан Республикасы законнары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяда “Татарстан Республикасы законнары,” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 29 сентябре
№ 71-ТРЗ